**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (муниципаль тур, 2023-2024 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 50 балл**

## I. Теоретик тестлар (10 балл).

1. Эпик, драма, лиро-эпик әсәрләрдә вакыйга-хәлләр яки кеше холкы-характерының үсү-үзгәрү тарихы (1 балл):
1) вакыйгалылык
2) сюжет
3) сюжет элементлары

2. Мәгънә ягыннан капма-каршы булган төшенчә яисә образларны белдерүче стилистик фигура (1 балл):
1) антитеза
2) антоним
3) эпитет

3. Лирик әсәрләр генә күрсәтелгән рәтне сайлап алыгыз (1 балл):
1) «Җырларым», «Хикмәтләр», «Нуры содур»
2) «Ышанма», «Сагыну», «Төхфәи мәрдан»
3) «Җырларым», «Хикмәтләр», «Ышанма»

4. Күрсәтелгән образлар арасыннан кайсы әсәрдә символ вазифасын үти (1 балл):
1) Ф.Әмирханның «Хәят» әсәрендә бакча
2) М.Җәлилнең «Кошчык» шигырендә кош
3) Г.Кутуйның «Сагыну» әсәрендә туган ил

5. Әдәбиятның кешене башка кешеләр һәм вакыйгалар уртасында тасвирлауга корылган төре (1 балл):
1) драматургия
2) проза
3) повесть

6. Лиро-эпик әсәрләр генә булган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) «Төхфәи мәрдан», «Хөсрәү вә Ширин», «Сагыну»
2) «Нуры содур», «Хөсрәү вә Ширин», «Җырларым»
3) «Төхфәи мәрдан», «Кыйссаи Йосыф», «Хәят»

7. Билгеләмәне игътибар белән укыгыз һәм аңа туры килгән төшенчәне язып куегыз: «*Билгеле бер идеал яктылыгында тормышны үзгәртеп тасвирлауга нигезләнгән иҗат юнәлеше, тибы*» (2 балл):

Җавап: _____________

8. Жанрларны лириклыктан эпиклыкка күчә бару тәртибендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны гына үсә бару тәртибендә языгыз (2 балл):

1) нәсер
2) пейзаж лирикасы
3) повесть

Җавап:_______

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## II. Әдип иҗатына кагылышлы биремнәр (30 балл).

1. Гомерен милләткә багышлаган шәхесләрнең берсе. Ул җирдә яшәвенең максатын татар әдәбиятын яңа баскычка күтәрүдә таба, милләтен алдынгы һәм бәхетле итеп күрергә тели. Аның зәвыклы, дөньяны-яшәешне күреп кенә түгел, тоеп һәм сиземләп аңлатучы бай күңеле, язмыш сынауларына бирешмәгән көчле рухы, әдәбиятта яңа сукмаклар салган проза әсәрләре бүгенге укучыны да үзенә җәлеп итә. Кем турында сүз бара? (2 балл):

Җавап:_______

2. Ф.Әмирхан кайсы өлкәләрдә эшли (1 балл):
1) проза, драматургия, поэзия, журналистика
2) проза, драматургия, әдәби тәнкыйть, поэзия
3) проза, драматургия, әдәби тәнкыйть, журналистика

3. Ф.Әмирханның «Хәят» әсәреннән алынган әлеге өзекнең төп фикере нинди? Дөрес җавапны билгеләгез (2 балл):

...*Салихның да кулында, теге егетнеке шикелле, бер думбрасы бар икән. Ул, шул думбрага бик матур чиертеп, кычкырып җырлап, Хәят утырган тәрәзәгә таба килә икән...*

*Салихның «Сөям сине» дигән, сүзсез җырлана торган җыры бөтен бакчаны яңгыратса да, Хәяттан башкаларга: Борһан абзый, Газизә абыстай һәм Бибигә ишетелми икән, ләкин Хәятка аермачык ишетелә икән....*

*Боларны хыялына китергәч, Хәят чынлап та кытыкланып китте, кызарынды һәм, үз-үзеннән оялып, мендәренә барып капланды да:*

*– Илаһи, мәхәббәт бир! Илаһи, гомерлек мәхәббәт бир инде! – диенде.».*

1) Мәхәббәт хыял белән бергә яши
2) Кешенең үзе яраткан кешесе белән тормыш корырга, бәхетле булырга хакы бар, ләкин татар тормышы чикләнгән
3) Мәхәббәт – илаһи көч

4. Ф.Әмирханның «Хәят» әсәреннән алынган әлеге өзекләр нинди теоретик төшенчәгә туры килә (2 балл):

*«Матур бу кызның озын керфекле кара күзләре алсу-ак йөзенә, могҗизалы якутлар шикелле, нур чәчеп торганлыктан, гүзәл башы, хәтта бөтен буе нурда йөзә шикелле күренә иде»; «Ул озын, куе вә үз-үзләреннән күперенеп тора торган, кара ефәк көлтәсе шикелле чәчләрен тараганда ...; Хәят әле бары уналтынчыда гына булса да, быел кыш ул, кинәт үсеп китеп, буе-сыны белән инде «җиткән» кызлардан аермасыз булган иде... Аның быел тектергән ал ефәк декольте күлмәге инде җиткән кызлар кия торган модаларның иң соңгысы белән тегелгән иде».*

Җавап:_______

5. Ф.Әмирхан иҗат дәвамында кайсы газета-журналлар белән эш итә (1 балл):
1) «Кояш», «Аң»
2) «Кояш», «Казан утлары»
3) «Ватаным Татарстан», «Ялт-Йолт»

6. Ф.Әмирхан әдәбиятның кайсы чорында актив иҗат эше белән шөгыльләнә? Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):
1) XIX гасыр ахыры
2) XX йөз башы
3) 1920 еллар

7. Ф.Әмирханның «Хәят» әсәре әдәбиятның кайсы төренә һәм жанрына карый? (2 балл):

Җавап:_______

8. Ф.Әмирханның «Хәят» әсәреннән алынган әлеге өзектә кулланылган 2 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз (4 балл):

... *Михаил да, Лиза шикелле үк, Хәятның кечкенәдән бергә уйнап үскән иптәше иде. Ул, үткән көз Казан университетына кабул ителгәнлектән, бу кышны Казанда уздырып, кичә генә N шәһәренә кайткан иде.*

*Алар өчәүләшеп яр өстеннән Иделгә карап тора торган эскәмиягә килеп утырдылар. Иделнең киңлеге, иркенлеге һәм көчле агышы, аның өстендәге пароходчыклар һәм ал арга тагылган баржалар, төрле җирләргә таралган, бер яктан икенче якка чыгарга азаплана торган көймәләр, икенче якта күренеп тора торган авыл һәм аның кыры һәм көтүе иркен һәм матур күренәләр иде...*

*Әнә бер кеше йөртә торган (пассажирский) пароход, аның көпчәк тавышы Идел өстен яңгырата, морҗасыннан чыккан кара төтене, артында калып, һәм һаваларга күтәрелә, һәм дулкыннарга кадәр төшә, ләкин шул ничә йөз кеше төягән пароход моннан бик кечкенә күренә, өстендәге кешеләре чыпчыклар кадәр генә... Кояш, шул биек кояшның күз чагылдыргыч шәүләсе, пароходчык калдырган дулкынчыкларда сикеренеп, чумып, шаярып йөри..*

Җавап:_______

9. Әлеге өзектә Хәятнең кичерешләрен ачу барышында Ф.Әмирхан нинди образлардан файдалана? (3 балл):

*...Төн килде. Бөтен табигать, бөтен җир йөзе, бөтен яшь йөрәкләр шикелле Хәят та язгы төннәрне сөя иде. Язның салкынчарак, хуш исле төннәре, бигрәк тә ул төннәрнең шундый хуш исле булучылыгы Хәятның йөрәгендә үзенә белемсез бер тойгы уята иде. Бу тойгыда җиңелчә генә моң, җиңелчә генә шатлык, нәрсәнедер җиңелчә генә сагыну, нәрсәнедер җиңелчә генә көтү, нәрсәгәдер җиңелчә генә куану, тагы әллә нәтэсәләр бар иделәр. Хәят язгы төннәрдә бу тойгы белән исерә дә, үз-үзен онытып, томанлы рәхәтлек эченә батып кала иде.*

*Бүген төн Хәятка, үзенең салкынчарак кына аязлыгы, язлыклы хуш исе эченә төрендереп, катгый бер карар да китерде.*

*Хәят, һәр көнге гадәтенчә, бакчага ачылган тәрәзәсе төбенә килеп утырды да, бакчадан керә торган салкынча һаваны зур-зур йотымнар белән эчеп, әлеге үзенә билгесез тойгының томанлы рәхәтлегенә талды. Һәм, шул томанлы рәхәтлек эченә төренеп, иртәдән бирле башын әйләндергән мәсьәләне салмак һәм тыныч кына чишеп ташлады.*

*Карар булды: Хәят Салихка барырга риза! Салихка баргач, бу соңгы айларда була башлаган эч пошу бәласе дә бөтенләй бетәчәк булды. Чөнки Хәят тормышының тойгы белән генә беленә торган китек ягын Салих бөтенләй тутырачак...*

10. Әлеге өзектә Хәятнең кичерешләрен сурәтләп, язучы нинди фикерләр җиткерә, нинди проблемалар күтәрә? (6 балл)

11. Фатих Әмирхан иҗатына хас 3 сыйфатны, үзенчәлекне атагыз (6 балл):

1) үз иҗатында нинди геройларга зур урын бирә?

2) нинди проблемалар күтәрә?

3) нинди алымнарга еш мөрәҗәгать итә?

## III. Иҗади бирем (10 балл).

«Акыллы ир «олугъ мин» дип лаф ормас / Аның затында алдау, хыянәт булмас...» юлларына нигезләнеп, 15 җөмләдән ким булмаган күләмдәге инша языгыз.